**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 29 маендагы 1825 номерлы карары**

# Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 27 августындагы 2752 номерлы «2025-2030 елларга Казан шәһәренең социаль сәясәте үсешенә булышлык итү һәм социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларга ярдәм күрсәтү буенча муниципаль программа турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясы нигезендә, 2025-2030 елларда Казан шәһәренең социаль сәясәте үсешенә булышлык итү һәм социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларга ярдәм күрсәтү чараларының нәтиҗәлелеген арттыру максатыннан, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 8 августындагы 4720 номерлы «Казан шәһәре муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында»гы карары таләпләрен исәпкә алып, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 27 августындагы 2752 номерлы «2025-2030 елларга Казан шәһәренең социаль сәясәте үсешенә булышлык итү һәм социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларга ярдәм күрсәтү буенча муниципаль программа турында»гы карары белән расланган 2025-2030 елларга Казан шәһәренең социаль сәясәте үсешенә булышлык итү һәм социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларга ярдәм күрсәтү буенча муниципаль программага (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. I «Программаның паспорты» бүлегендә:

1.1.1. «Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бирергә:

<table>
<tr>
<td>Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары</td>
<td>Программаны финанслау күләме 159 007,999 мең сум тәшкил итә, шуларның 159 007,999 мең сумы – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары хисабына.
<table>
<tr><th rowspan="2">Ел</th><th colspan="3">Акчалар күләме, мең сумнарда</th></tr>
<tr><th>Барлыгы</th><th>Муниципаль бюджет акчалары</th><th>Бюджеттан тыш чыганаклар</th></tr>
<tr><td>2025</td><td>26507,999</td><td>26507,999</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2026</td><td>27700,0</td><td>27700,0</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2027</td><td>26200,0</td><td>26200,0</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2028</td><td>26200,0</td><td>26200,0</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2029</td><td>26200,0</td><td>26200,0</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2030</td><td>26200,0</td><td>26200,0</td><td>-</td></tr>
<tr><td>БАРЛЫГЫ</td><td>159 007,999</td><td>159 007,999</td><td>-</td></tr>
</table>
Искәрмә: финанслау күләмнәре фаразлау характерында бирелә һәм аларга, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»</td>
</tr>
</table>

1.1.2. «Программаны гамәлгә ашырудан көтелгән нәтиҗәләр» юлын түбәндәге редакциядә бирергә:

| | |
|---|---|
| «Программаны гамәлгә ашырудан көтелгән нәтиҗәләр | Программаны гамәлгә ашыру:<br>- Казан шәһәре җирле үзидарә органнары һәм Казан шәһәренең муниципаль учреждениеләре белән хезмәттәшлек итүче социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар санын арттырырга;<br>- муниципаль милек ярдәме күрсәтелгән социаль юнәлештәге коммерция нигезләнмәгән оешмалар санын саклап калырга;<br>- Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре тарафыннан социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар белән берлектә уздырыла торган чаралар санын 3 тапкырга арттырырга;<br>- Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, җирле массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырылган, социаль юнәлештәге коммерциягә |

| | |
|---|---|
| | нигезләнмәгән оешмалар эшчәнлеген яктырта торган мәгълүмати материаллар санын арттырырга;<br>- социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар катнашында уздырылган семинарлар, утырышлар, киңәшмәләр, конференцияләр һәм башка чаралар санын 75 процентка арттырырга;<br>- социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларның социаль юнәлешле проектларына ел саен муниципаль ярдәм күрсәтүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк» |

1.2. III «Программаның максатлары һәм бурычлары, программа чаралары. Көтелә торган ахыргы нәтиҗәләрне тасвирлау, Программаны гамәлгә ашыру сроклары» бүлегендә 9-16 абзацларны түбәндәге редакциядә бирергә:

«Программаны гамәлгә ашырудан көтелә торган ахыргы нәтиҗәләр:

- Казан шәһәре җирле үзидарә органнары һәм Казан шәһәренең муниципаль учреждениеләре белән хезмәттәшлек итүче социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар саны арту;

- муниципаль милек ярдәме күрсәтелгән социаль юнәлештәге коммерция нигезләнмәгән оешмалар санын саклап калу;

- Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре тарафыннан социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар белән берлектә уздырыла торган чаралар саны арту;

- Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, җирле массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырылган, социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар эшчәнлеген яктырта торган мәгълүмати материаллар саны арту;

- социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар катнашында уздырылган семинарлар, утырышлар, киңәшмәләр, конференцияләр һәм башка чаралар саны 75 процентка арту;

- социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларның социаль юнәлешле проектларына ел саен муниципаль ярдәм күрсәтүне тәэмин итү»;

1.3. IV «Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү» бүлегендә 1, 2 абзацларны түбәндәге редакциядә бирергә:

«Программаны финанслау күләме 159 007,999 мең сум тәшкил итә.

| Ел | Акчалар күләме, мең сумнарда | | |
|---|---|---|---|
| | **Барлыгы** | **Муниципаль бюджет акчалары** | **Бюджеттан тыш чыганаклар** |
| **2025** | **26507,999** | **26507,999** | - |
| **2026** | **27700,0** | **27700,0** | - |
| **2027** | **26200,0** | **26200,0** | - |
| **2028** | **26200,0** | **26200,0** | - |
| **2029** | **26200,0** | **26200,0** | - |
| **2030** | **26200,0** | **26200,0** | - |
| **Барлыгы** | **159 007,999** | **159 007,999** | - |

Искәрмә: финанслау күләмнәре фаразлау характерында бирелә һәм аларга, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»;

1.4. Программага 1 һәм 2 номерлы кушымталарны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.5. әлеге карарга 1 һәм 2 номерлы кушымталарны Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 27 августындагы 2752 номерлы карары белән расланган Программага, шул ук тәртиптә, 1 һәм 2 номерлы кушымталар дип санарга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.И.Абзаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 29 маендагы
1825 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**2025-2030 елларга Казан шәһәренең социаль сәясәте үсешенә булышлык итү һәм социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларга ярдәм күрсәтү буенча муниципаль программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм финанс чараларын бүлү**

| **Программа максатлары: коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларның социаль юнәлешле эшчәнлеген стимуллаштыру һәм халыкның социаль яктан якланмаган категорияләренә ярдәм итү** | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **1 бурыч. Социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларны үстерүгә һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга ярдәм итү** | | | | | | | |
| **Индикаторлар күрсәткече** | | | | | | | |
| **Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре** | **2024 ел (база елы)** | **2025 ел** | **2026 ел** | **2027 ел** | **2028 ел** | **2029 ел** | **2030 ел** |
| Милек ярдәме алучы социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар саны (бер елга барлыгы), бер. | 60 | 60 | 60 | 60 | 60 | 60 | 60 |
| Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар эшчәнлеге турында мәгълүмат булу-булмау (әйе/юк) | әйе | әйе | әйе | әйе | әйе | әйе | әйе |
| Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында түгәрәк өстәлләр, семинарлар үткәрү, грантлар турында мәгълүмат урнаштыру (әйе/юк) | әйе | әйе | әйе | әйе | әйе | әйе | әйе |
| Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларны социальләштерүне гамәлгә ашыра | - | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| торган, чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен субсидия бирелгән социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар саны | | | | | | | |

| **Төп чараларның атамалары** | **Башкаручылар** | **Төп чараларны башкару вакыты** | **Финанслау, мең сумнарда** | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | **2025** | **2026** | **2027** | **2028** | **2029** | **2030** |
| 1.1. Грант ярдәме алган социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларга социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтү | Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, «Игелекле Казан» оешмасы (килешү буенча) | Даими рәвештә | - | - | - | - | - | - |
| 1.2. Гамәлдәге законнар һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларга коммерция һәм эшмәкәрлек белән бәйле булмаган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен бушлай файдалану хокукында муниципаль милек бирү юлы белән милек ярдәме күрсәтү | Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты, районнар администрацияләре | Даими рәвештә | Агымдагы эшчәнлек кысаларында | | | | | |
| 1.3. Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларны социальләштерүне гамәлгә ашыра торган социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) субсидия | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты | Ел саен | 15 000 | 26 200 | 26 200 | 26 200 | 26 200 | 26 200 |
| 1.4. «Игелекле Казан» коммерциягә нигезләнмәгән автоном оешмасы коворкингы базасында коммуникатив, шул исәптән коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар лидерлары, волонтерлар, бухгалтерлар, | «Игелекле Казан» оешмасы (килешү буенча) | Ихтыяҗ булган саен | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| фандрайзерлар һәм башкалар өчен очрашулар мәйданчыклары оештыру | | | | | | | | |
| 1.5. Социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларга түгәрәк өстәлләр, семинарлар, тематик чаралар (концертлар, конкурслар, фестивальләр) оештыруда, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге проектларны гамәлгә ашыруда мәгълүмат-консультация ярдәме күрсәтү | Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, «Игелекле Казан» оешмасы (килешү буенча) | Ихтыяҗ булган саен | - | - | - | - | - | - |
| 1.6. Социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларга социаль әһәмияткә ия чаралар үткәрү өчен урыннар (мәйданчыклар) бирүдә ярдәм күрсәтү | Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре | Ихтыяҗ булган саен | - | - | - | - | - | - |
| 1.7. Социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларны үстерү, эш тәҗрибәсе белән уртаклашу, программаларны һәм проектларны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча конференцияләр, форумнар, фестивальләр оештыруда һәм уздыруда ярдәм күрсәтү | Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре | Ихтыяҗ булган саен | - | - | - | - | - | - |
| 1.8. Социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар активының төрле категорияләре өчен фандрайзинг, ирекләләр хәрәкәте, социаль эшмәкәрлек һәм башка мәсьәләләр буенча уку-укыту программалары циклларын (семинарлар, тренинглар, курслар) уздыруда ярдәм итү | Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, «Игелекле Казан» оешмасы (килешү буенча) | Ихтыяҗ булган саен | - | - | - | - | - | - |
| 1.9. Иҗтимагый хәрәкәтләр активистлары өчен Казан шәһәренең истәлекле урыннары буйлап экскурсияләр оештыру | Казан шәһәренең туризмны үстерү комитеты | Ихтыяҗ булган саен | - | - | - | - | - | - |
| 1.10. Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган ярдәмнән файдаланучы социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты | Даими рәвештә | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| реестрын алып бару һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында урнаштыру | | | | | | | | |
| 1.11. Социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларга муниципаль берәмлек органнары белән эшчәнлекнең һәм хезмәттәшлекнең актуаль мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирү | Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, «Игелекле Казан» оешмасы (килешү буенча) | Даими рәвештә | - | - | - | - | - | - |
| 1.12. Социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар эшчәнлеге турында мәгълүматны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында урнаштыру һәм аларның эшчәнлеген, хәйриячелек һәм ирекләләр хәрәкәтен массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуда ярдәм итү | Казан шәһәре иҗтимагый үзәге, Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсе (килешү буенча) | Даими рәвештә | - | - | - | - | - | - |
| 1.13. Социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларга устав белән каралган эшчәнлекләренә ирекләләрне җәлеп итүдә ярдәм күрсәтү | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, Мәгариф идарәсе | Даими рәвештә | - | - | - | - | - | - |
| 1.14. Өлкән яшьтәге волонтерларны социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар эшчәнлегенә җәлеп итү | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, «Игелекле Казан» оешмасы (килешү буенча) | Ихтыяҗ булган саен | - | - | - | - | - | - |
| 1.15. Татарстан Республикасының башка шәһәрләрендәге һәм Россия Федерациясе шәһәрләрендәге ветераннар оешмалары белән очрашулар оештыруда, Казан шәһәре ветераннарының (пенсионерларының) Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе шәһәрләренә һәм районнарына сәфәрләрен оештыруда ярдәм итү | Казан шәһәренең туризмны үстерү комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Казан шәһәренең ветераннар (инвалидлар) оешмасы (килешү буенча) | Ихтыяҗ булган саен | - | - | - | - | - | - |

**2 бурыч. Халыкның социаль яктан якланмаган категорияләренең тормыш сыйфатын күтәрүдә ярдәм күрсәтү, өлкән яшьтәге кешеләрнең озак еллар актив булып калуына булышлык итү**

**Индикаторлар күрсәткече**

| **Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре** | **2024 ел (база елы)** | **2025 ел** | **2026 ел** | **2027 ел** | **2028 ел** | **2029 ел** | **2030 ел** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Яшәү яме» проекты аудиториясен колачлау, кеше | 620 000 | 630 000 | 632 000 | 634 000 | 636 000 | 638 000 | 640 000 |
| «Яшәү яме» проекты кысаларында үткәрелгән чаралар саны, бер. | 1700 | 1750 | 1780 | 1800 | 1820 | 1840 | 1860 |

| **Төп чараларның атамалары** | **Башкаручылар** | **Төп чараларны башкару вакыты** | **Финанслау, мең сумнарда** | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | **2025** | **2026** | **2027** | **2028** | **2029** | **2030** |
| 2.1. «Яшәү яме» шәһәр социаль проектын үстерү, шул исәптән: | Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Казан шәһәренең ветераннар (инвалидлар) оешмасы (килешү буенча), «Игелекле Казан» оешмасы (килешү буенча) | Даими рәвештә | - | - | - | - | - | - |
| 2.1.1. «Яшәү яме» газетасын чыгуы | Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсе (килешү буенча), Казан шәһәренең ветераннар (инвалидлар) оешмасы (килешү буенча), | Кварталга бер тапкыр | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | «Игелекле Казан» оешмасы (килешү буенча) | | | | | | | |
| 2.1.2. «Кешеләр һәм еллар» очрашуларын оештыру һәм уздыру | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Мәдәният идарәсе, Казан шәһәренең ветераннар (инвалидлар) оешмасы (килешү буенча), «Игелекле Казан» оешмасы (килешү буенча) | Кварталга бер тапкыр | - | - | - | - | - | - |
| 2.1.3. «Йөзьяшәрләр уеннары. Яшәү яме» проектын гамәлгә ашыру | Физик культура һәм спорт комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитетының районнар администрацияләре, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Казан шәһәренең ветераннар (пенсионерлар) оешмасы (килешү буенча), «Игелекле Казан» оешмасы (килешү буенча) | Аерым график буенча | 6567, 999 | * | * | * | * | * |
| 2.1.4. «Яшәү яме көне» шәһәр бәйрәмен оештыру һәм уздыру | Мәдәният идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Казан шәһәренең ветераннар | Елга бер тапкыр | * | * | * | * | * | * |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | (пенсионерлар) оешмасы (килешү буенча), «Игелекле Казан» оешмасы (килешү буенча) | | | | | | | |
| 2.1.5. «Яшәү яме» проекты активистлары өчен күчмә лагерь сменасы оештыру һәм үткәрү | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Казан шәһәренең ветераннар (пенсионерлар) оешмасы (килешү буенча), «Игелекле Казан» оешмасы (килешү буенча) | Аерым план буенча | * | * | * | * | * | * |
| 2.2. Инвалидлар декадасын үткәрү кысаларында гражданнарның аерым категорияләренә бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү (район комиссияләренә иҗтимагый оешмалар вәкилләрен җәлеп итеп, Казан шәһәре Башкарма комитетының аерым карары буенча) | Казан шәһәре Башкарма комитетының районнар администрацияләре | Елга бер тапкыр (IV квартал) | 3440 | * | * | * | * | * |

**3 бурыч. Патриотик тәрбия бирүгә һәм социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларның җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлеген киңәйтүгә булышлык итү**

**Индикаторлар күрсәткече**

| Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | 2024 ел(база елы) | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Казан шәһәре Башкарма комитеты бүлекчәләре тарафыннан социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар белән берлектә уздырылган чаралар саны, бер. | 8 | 10 | 12 | 15 | 17 | 20 | 25 |
| Балаларга һәм яшьләргә хәрби-патриотик һәм әхлакый тәрбия бирү, Бөек Ватан сугышында Җиңү турындагы, Ватанны саклап һәлак булган сугышчылар турындагы истәлекне мәңгеләштерү, балаларда һәм яшьләрдә өлкән буынга карата ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү мәсьәләләре буенча ветераннар белән оештырылган очрашулар саны, очрашулар | 80 | 130 | 135 | 140 | 145 | 150 | 155 |
| Социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар катнашында Казан шәһәре Башкарма комитеты бүлекчәләре тарафыннан уздырылган семинарлар, утырышлар, киңәшмәләр, конференцияләр һәм башка чаралар саны, бер. | 8 | 8 | 10 | 10 | 12 | 12 | 14 |

| **Төп чараларның атамалары** | **Башкаручылар** | **Төп чараларны башкару вакыты** | **Финанслау, мең сумнарда** | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | **2025** | **2026** | **2027** | **2028** | **2029** | **2030** |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| 3.1. Казан шәһәре Башкарма комитеты бүлекчәләре тарафыннан социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар белән берлектә шәһәр һәм район күләмендәге чараларны (мәдәни-агарту, хәйрия, патриотик, спорт-сәламәтләндерү, этно-конфессиональ юнәлештәге) оештыру һәм үткәрү, шул исәптән | Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, «Игелекле Казан» оешмасы (килешү буенча) | Даими рәвештә | - | - | - | - | - | - |
| 3.1.1. «Язгы игелек атнасы» хәйрия акциясе | Казан шәһәре Башкарма | Елга бер тапкыр, апрель | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | комитетының структур бүлекчәләре, «Игелекле Казан» оешмасы (килешү буенча) | | | | | | | |
| 3.1.2. «Мәктәпкә әзерләнергә ярдәм ит» хәйрия акциясе | Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, «Игелекле Казан» оешмасы (килешү буенча) | III квартал | - | - | - | - | - | - |
| 3.2. Казан шәһәренең ветераннар (пенсионерлар) оешмасы, «Татарстан Геройлары» иҗтимагый оешмасы, махсус хәрби операциядә катнашучылар белән берлектә балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирүгә, Бөек Ватан сугышында Җиңү турындагы, Ватанны саклап һәлак булган сугышчылар турындагы истәлекне мәңгеләштерүгә, балаларда һәм яшьләрдә өлкән буынга карата ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрү | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, Мәгариф идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының районнар администрацияләре | Даими рәвештә | - | - | - | - | - | - |
| 3.3. Социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар катнашында түгәрәк өстәлләр, утырышлар, киңәшмәләр, конференцияләр һәм башка чаралар үткәрү | Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, «Игелекле Казан» оешмасы (килешү буенча) | Ихтыяҗ булган саен | - | - | - | - | - | - |
| 3.4. Социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар белән үзара хезмәттәшлек нәтиҗәләре буенча стратегик сессияләр үткәрү | Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, «Игелекле Казан» | Елга бер тапкыр (IV квартал) | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | оешмасы (килешү буенча) | | | | | | | |

**4 бурыч. Хәйриячелек эшчәнлегендә һәм иреклеләр хәрәкәтендә катнашуга стимуллаштыру һәм бүләкләү**

**Индикаторлар күрсәткече**

| Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | 2024 ел (база елы) | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Муниципаль ярдәм алган социаль юнәлешле проектларның саны, бер. | 0 | 9 | 9 | 9 | 9 | 9 | 9 |

| Төп чараларның атамалары | Башкаручылар | Төп чараларны башкару вакыты | Финанслау, мең сумнарда | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2025 | 2026 | 2027 | 2028 | 2029 | 2030 |
| 4.1. Социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар активын, хәйриячеләрне һәм иреклеләр хәрәкәтендә катнашучыларны бүләкләү, шул исәптән мактау грамоталары, рәхмәт хатлары һәм башкалар белән бүләкләү формаларын үстерү | Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, «Игелекле Казан» оешмасы (килешү буенча) | Ихтыяҗ булган саен | - | - | - | - | - | - |
| 4.2. Казан шәһәре Мэры премиясенә ел саен үткәрелә торган «Игелекле эшләр шәһәре» конкурсын оештыру һәм уздыру | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, «Игелекле Казан» оешмасы (килешү буенча) | Ел саен | 1500 | 1500 | * | * | * | * |
| 4.3. «Игелекле Казан» форумын оештыру һәм уздыру | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур | Өч елга бер тапкыр | - | * | - | - | * | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | бүлекчәләре, «Игелекле Казан» оешмасы (килешү буенча) | | | | | | | |
| 4.4. Инклюзив белем бирү өлкәсендә «Игелекле Казан» шәһәр премиясен оештыру һәм үткәрү | Мәгариф идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, «Игелекле Казан» оешмасы (килешү буенча) | Ике елга бер тапкыр | - | * | - | * | - | * |
| **Программа буенча барлыгы, шул исәптән** | | | **26 507,999** | **27700,0*** | **26200,0*** | **26200,0*** | **26200,0*** | **26200,0*** |
| **Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары хисабына** | | | **26507,999** | **27700,0*** | **26200,0*** | **26200,0*** | **26200,0*** | **26200,0*** |
| **Бюджеттан тыш акчалар хисабына** | | | **-** | **-** | **-** | **-** | **-** | **-** |

Искәрмә: * – финанслау чыганаклары булган очракта.

**Файдаланылган кыскартулар исемлеге**:

«Игелекле Казан» оешмасы – «Игелекле Казан» коммерциягә нигезләнмәгән автоном оешмасы;

Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты – Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты;

Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты – Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты;

Казан шәһәренең туризмны үстерү комитеты – «Казан шәһәренең туризмны үстерү комитеты» муниципаль казна учреждениесе;

Физик культура һәм спорт комитеты – Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитеты;

Казан шәһәренең ветераннар (пенсионерлар) оешмасы – Казан шәһәре ветераннарының (пенсионерларының) җирле иҗтимагый оешмасы;
Казан шәһәре иҗтимагый үзәге – «Казан шәһәре иҗтимагый үзәге» муниципаль казна учреждениесе;
Мәдәният идарәсе – Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе;
Мәгариф идарәсе – Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе.

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 29 маендагы
1825 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**2025-2030 елларга Казан шәһәренең социаль сәясәте үсешенә булышлык итү һәм социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларга ярдәм күрсәтү буенча муниципаль программа чараларын гамәлгә ашыруга Казан шәһәре бюджетыннан акчалар бүлү**

(мең сумнарда)

| Бюджет чараларын төп бүлүчеләр | Программа пунктлары | Программа чараларын финанслау | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | **2025** | **2026** | **2027** | **2028** | **2029** | **2030** |
| Казан шәһәре Башкарма комитетының районнар администрацияләре | 2.2. Инвалидлар декадасын үткәрү кысаларында гражданнарның аерым категорияләренә бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү (район комиссияләренә иҗтимагый оешмалар вәкилләрен җәлеп итеп, Казан шәһәре Башкарма комитетының аерым карары буенча) | 3440 | * | * | * | * | * |
| Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты | 1.3. Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларны социальләштерүне гамәлгә ашыра торган социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) субсидия | 15000 | 26200 | 26200 | 26200 | 26200 | 26200 |
| | 4.2. Казан шәһәре Мэры премиясенә ел саен үткәрелә торган «Игелекле эшләр шәһәре» конкурсын оештыру һәм уздыру | 1500 | 1500 | * | * | * | * |
| Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитеты | 2.1.3. «Йөзьяшәрләр уеннары. Яшәү яме» проектын гамәлгә ашыру | 6567,999 | * | * | * | * | * |
| **БАРЛЫГЫ** | | **26507,999** | **27700,0 *** | **26200,0 *** | **26200,0 *** | **26200,0 *** | **26200,0 *** |

Искәрмә: * - финанслау чыганаклары булган очракта.

________________